**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**
**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы**
**«Спас авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче**
**Спас авылы**

2024 елның 23 ноябре №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы районы Бөгелмә муниципаль берәмлегенең «Спас авыл җирлеге» Спас авылы торак пунктындагы гражданнар җыены нигезендә

**карар кылды:**

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Спас авыл җирлеге» Спас авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, ветераннардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, тыл хезмәтчәннәреннән, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган) төзүгә, ремонтлауга һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерүгә (1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәйкәлен реконструкцияләү Спас авылы).

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**"Спас авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлек башлыгы** **А. С. Мухалев**